| | |
|---|---|
| **ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

5 ноябрь 2020 ел с. Ульянково №1

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан Ульянково мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 34а йорт адресы буенча урнашкан Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында 2020 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә
3. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан Ульянково мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2020 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан Ульянково

мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын 2020 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Ульянково авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

а) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

- су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллануга, суны анализлауга һәм башка документларны документаль рәсмиләштерү

б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту»

в) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- кирәкле материаллар сатып алынган күперләрне ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Ульянково авыл жирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**